Батырлыкта- матурлык

**АННАТОЦИЯ**

Ш.Рәкыйпов иҗаты 1960 – 2000 еллар татар әдәбиятында ныклы һәм үзенчәлекле урын алып тора. XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты үз үсешенең шактый югары дәрәҗәсенә ирешкән вакытта мәйдан тотып, кырык елга якын иң актив иҗат итүче авторларның берсе булган прозаикның әсәрләре, бердәм агымга кушылып, гомуми казанышларның җитди өлешен тәшкил иттеләр. Алар шул чорның җанлы әдәби тәнкыйтенең дә игътибар үзәгендә булдылар.

Бу чор татар әдәбиятында Бөек Ватан сугышы темасы үзәк урыннарның берсен алып тора. Әсәрләрдә ут ялкыны эчендә, үлем белән кара-каршы очрашкан сугышчыларыбызның бөтен асыл сыйфатлары – эчке рухларының матурлыгы, батырлыклары, олы җанлы һәм көчле ихтыярлы булулары ачыла. Язучыларыбыз аларның үлмәс образларын тудыру юнәлешендә зур казанышларга ирештеләр. Киң катлау укучыларга кешелек тарихында тиңе булмаган бу сугышта җиңеп чыгуыбызның чын алшартларын да ачып бирергә кирәк иде. Язучылар моны тирән аңлап эш итәләр.

Яңа ачылган тормыш фактларына, документларга нигезләнеп, вакыйгаларны булганынча бирүдә киң мөмкинлекләр ачыла. Сугыш хакында укучы гадәтләнеп беткән күп кенә карашлар да үзгәрүгә дучар ителә. Шул сәбәпле кешеләрдә дә вакыйга-хәлләрнең чынлыкта ничек булганын белү теләге туа. Әдәбиятыбызга героик очерк жанрының яңадан әйләнеп кайтуын, документаль жанрларга – әдәби-документаль повесть, хикәя һәм иҗат итүнең активлашуын, әлеге ихтыяҗның нәтиҗәсе дип карарга кирәк. Ш.Рәкыйпов шушы жанрларда аеруча нәтиҗәле һәм эзлекле эшләп килүче язучыларыбызның берсе булды.